КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 15

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16+200 км – 21+977 км» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16+200 км – 21+977 км» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, «Казан» нәселле ат үстерү заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – җир кишшәрлекләре милекчесе) милкендә булган 590 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген 16:33:080712:265 кадастр саны белән һәм 1 289 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген 16:33:080712:266 кадастр саны белән (алга таба – җир кишәрлекләре) Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алу юлы белән алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен Татарстанның юл-транспорт идарәсенә, җир кишәрлекләре милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалына Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрүне;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләре өчен каплау күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

җир кишәрлекләре милекчесе тарафыннан имзаланган килешүләр законнар белән билгеләнгән вакытта бирелмәгән очракта, тиешле дәгъваларны судка бирүне.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин